РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ
ТИМБАЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТИМБАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«27» гыйнвар 2022 ел № 42-1

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Тимбай авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 20 пункты, Буа муниципаль районының Тимбай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге уставы нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Тимбай авыл җирлеге советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Тимбай авыл советының 2013 елның 20 февралендәге 1-39 номерлы «Буа муниципаль районының Тимбай авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре турында»гы карары белән расланган Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Тимбай авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә (27.06.2016 № 14-1, 23.09.2017 № 36-1, 13.02.2019 № 60-1, 22.06.2021 № 28-1 карарлары редакциясендә) (алга таба - Кагыйдәләр) киләсе үзгәрешләрне кертергә:

1) Кагыйдәләрнең IX өлешендәге III бүлекнең 30 статьясындагы 1.2 пунктында «Җир кишәрлекләренең тәкъдим ителә торган күләмнәрен» сүзләрен төшереп калдырырга һәм 1.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2 Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалануның иң чик параметрлары:

Кишәрлек размеры:

Җир кишәрлекләренең минималь һәм максималь күләмнәре Җирлек советы тарафыннан кабул ителә.

Җир кишәрлекләренең иң кечкенә размеры – 1000 кв.м.

Җир кишәрлекләренең иң зур размеры – 5000 кв.м.

Төзелешләрнең биеклеге:

Төп төзелештәге катларның иң чик саны - 3 кат (мансард катын да кертеп);

Төп төзелешнең иң чик биеклеге – 10 м.;

Ярдәмче корылмалар катларының иң чик саны – 1;

Ярдәмчел корылмаларның иң чик биеклеге - 3,5 м. (яссы түбәле), 4,5 м. (скат түбә, түдә очы биеклеге).

Коймаларның максималь биеклеге – 2,0 м.

Төзелеш коэффициенты:

Йорт тибындагы төзелеш коэффициенты – 0,2;

Блокланган йортлар төзү коэффициенты – 0,3.

Күрше кишәрлекләрендәге урамнардан һәм корылмалардан иң кечкенә ераклыклар:

урамнарның кызыл сызыгыннан алып торак йортка кадәр - 5м, юлларның кызыл сызыгыннан торак йортка кадәр – 3 м.;

күрше кишәрлекнең чикләреннән алып торак йортка кадәр – 3 м.;

торак бина тәрәзәләреннән алып күрше кишәрлектә урнашкан хуҗалык корылмаларына кадәр – кимендә 10 м.;

кишәрлек чигеннән алып хуҗалык корылмаларына кадәр – 1 м.;

бәдрәфтән күрше йортның диварына кадәр (үзәкләштерелгән канализация булмаганда) кимендә 12м;

бәдрәфтән (үзәкләштерелгән канализация булмаганда) су белән тәэмин итү чыганагына кимендә 25 м.»

2. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Тимбай авыл җирлегендә Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эш төркеме төзергә;

-эш төркеме җитәкчесе:

- эш төркеме әгъзалары:

Мөхәммәтшина Румия Шәйхи кызы -Тимбай авыл җирлеге башлыгының урынбасары;

Андреева Гульчачак Камил кызы-Тимбай авыл җирлеге секретаре;

Гыйльфанов Ринат Мансур улы-Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура бүлеге башлыгы;

Рахматов Булат Рафаэль улы-Буа муниципаль районы Советы Аппаратының юридик бүлеге башлыгы (килешү буенча).

3.Билгеләргә:

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Тимбай авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы карар проектына тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Тимбай авыл җирлеге Советына түбәндәге адрес буенча кертелә: ТР, Буа районы, Ташкичү авылы, Үзәк ур., 21 йорт В, язма рәвештә, карар проекты рәсми басылып чыккан көннән алып 30 көн эчендә, эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Тимбай авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы карар проекты буенча ачык тыңлауларда чыгыш ясау хокукы белән катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча тапшырыла: ТР, Буа районы, Ташкичү авылы, Үзәк ур., 21 йорт В, эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, ачык тыңлаулар үткәрү датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Тимбай авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы карар проекты буенча Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Тимбай авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә ачык тыңлаулары үткәрү турында нигезләмәдә каралган тәртиптә әлеге проект буенча ачык тыңлауларны 2022 елда “25” февральдә 10.00 сәгатьтә Тимбай авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында үткәрергә.

7. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/), шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (http://buinsk.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Буа муниципаль районы Тимбай авыл
җирлеге башлыгы, Совет рәисе Р.Ш. Мөхәммәтшина